Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы

# КАРАР

2020 елның 03 ноябреннән № 6

Аксубай муниципаль районының Яңа Аксубай авыл җирлегенең Яңа Аксубай торак пунктында гражданнар үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җыен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Яңа аксубай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә Аксубай муниципаль районы КАРАР БИРӘМ:

1.ТР, Аксубай районы, Яңа Аксубай авылы, Центральная урамы, 27 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында 2020 елнын 17 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегенең Яңа Аксубай торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2021 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яңа Аксубай авыл җирлеге Яңа Аксубай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә узсалым кертергә.

**1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- вак таш сатып алу;

- торак пункт чикләрендә юл полотносын төзү, шул исәптән туфрак күтәрү, грейдирование, вак таш сибү, тигезләү (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

-торак пункт эчендәге юлларны кышын карап тоту, шул исәптән: грейдирование, кардан арындыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.

**2.КККНЫ жыю ( шул исәптән аерым туплау) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:**

- каты көнкүреш калдыкларын жыю өчен контейнерлар сатып алу;

**3.Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә:**

- Яңа Аксубай торак пунктында су челтәрләрен ремонтлау (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3.Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм такталарда игъланнар такталарында элү юлы белән, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4.Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә

Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы

Аксубай муниципаль районы А.В.Макаров